**Республика Татарстан**
**Совет Новооимянского**
**сельского поселения**
**Сармановского**
**муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль**
**районының Яңа Имән**
**авыл җирлеге Советы**

---

**РЕШЕНИЕ** с.Кутемели **КАРАР**

12 ноябрь 2018 ел № 23

**«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затының хезмәткә түләү нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 28 апрелендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 28 мартындагы 940 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карары нигезендә, Сарман муниципаль районы Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затының хезмәткә түләү нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 28 апрелендәге 4 номерлы Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Советы карарына үзгәреш кертергә.

1. 1 нче кушымтаның 3 пунктындагы 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Яңа Имән авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затының хезмәткә түләү чыгымнары елына айлык акчалата бүләкләүне түләү өлешендә 6.72 айлык акчалата бүләкләүне тәшкил итә.

2. 2018 елның 01 октябрендәге штат расписаниесен расларга һәм һәм яңадан исәпләп чыгарырга.

3. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының сайланулы вазыйфаи Яңа Имән авыл җирлегенең хезмәт өчен түләү нигезләмәсенә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 20 июнендәге 7 номерлы карарын юкка чыгарырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» http://pravo.tatarstan.ru һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында http:/ sarmanovo.tatarstan.ru адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2018 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Яңа Имән авыл җирлеге
Советы рәисе Р.Ф.Гараев